КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 10 декабрь г.Казань № 1133

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү турында» 2014 ел, 2 сентябрь, 635 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү турында» 2014 ел, 2 сентябрь, 635 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 20 февраль, 103 нче; 2015 ел, 10 декабрь, 932 нче; 2017 ел, 14 ноябрь, 873 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге ФЗ-178 номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 15 апрелендәге 296 номерлы карары нигезендә, шулай ук тормышта авыр хәлдә калган затларга адреслы социаль ярдәм күрсәтү формаларының нәтиҗәлелеген арттыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмәдә:

1.1 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында халыкның тиешле социаль-демографик төркемнәре өчен билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән түбәнрәк булган аз керемле гаиләгә һәм ялгыз яшәүче аз керемле гражданга, әгәр дә

аз керемле гаилә әгъзалары һәм ялгыз яшәүче аз керемле граждан яше, сәламәтлеге буенча эшкә сәләтсез булса, дәүләт социаль ярдәме социаль контракт төземичә күрсәтелә.»;

1.7 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.7. Социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү өч айдан алып бер елга кадәр социаль адаптацияләү программасы эчтәлегеннән чыгып (бу пунктның бишенче – сигезенче абзацларында каралган очраклардан тыш) билгеләнә.

Граждан тарафыннан социаль контракт шартларын үтәүгә комачаулый торган уңай сәбәпләр булганда, әлеге вакыт территориаль социаль яклау органы тарафыннан озайтылырга, әмма иң күбе 6 айга озайтылырга мөмкин.

Социаль контракт вакытын озайту өчен нигезләр: авыру (стационар дәвалану); якын туганнары вафат булу (ата-анасы, балалары, ире (хатыны); табигый бәла-каза; гражданның үз өстенә алган бурычларын үти алырга сәләтсез булуга бәйле булган башка гадәттән тыш вакыйгалар.

Социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме түбәндәгеләргә билгеләнә:

18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган гаиләләргә (атасы йә анасы инвалид булган һәм (яки) балаларының берсе инвалид бала булган гаиләләрдән тыш) – алты айга;

эш эзләүдә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә социаль контракт төзегән һәм социаль адаптацияләү программасында билгеләнгән вакытта эшкә урнашкан гражданнарга – бер елга;

һөнәри белем алганда яки өстәмә һөнәри белем алганда дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә социаль контракт төзегән гражданнарга – уку чорына, әмма иң күбе өч айга;

һөнәри белем алганда яки өстәмә һөнәри белем алганда эш бирүчедә алга таба стажировка үтү шарты белән дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә социаль контракт төзегән гражданнарга – стажировка үтү чорына тугыз айга кадәр.»;

1.11 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.11. Социаль контракт гамәлдә булган чорга айлык социаль пособие күләме:

18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган гаиләләр әгъзалары өчен (атасы йә анасы инвалид булган һәм (яки) балаларының берсе инвалид бала булган гаиләләрдән тыш) социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында гариза тапшырган көнгә аз керемле гаиләнең яшәү минимумы күләме һәм аз керемле гаиләнең җан башына уртача кереме арасындагы аерма чикләрендә билгеләнә;

эш эзләүдә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә социаль контракт төзегән һәм социаль адаптацияләү программасында билгеләнгән вакытта эшкә урнашкан, шулай ук һөнәри белем алганда яки өстәмә һөнәри белем алганда дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә социаль контракт төзегән гражданнар өчен Татарстан Республикасында социаль контракт төзегән елга кадәрге елның II кварталына билгеләнгән эшкә сәләтле халык өчен яшәү минимумы күләменә тигез була;

һөнәри белем алганда һәм өстәмә һөнәри белем алганда дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә социаль контракт төзегән гражданнар өчен, эш бирүчедә алга таба стажировка үткән очракта, тиешле елга Татарстан Республикасында билгеләнгән хезмәт өчен түләүнең бюджеттан тыш дәүләт фондларына иминият кертемнәренә арттырылган минималь күләме зурлыгына тигез була.

Социаль контрактта күздә тотылган бер тапкыр бирелә торган түләү күләме гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) социаль адаптацияләү программасы чараларын исәпкә алып билгеләнә, әмма ялгыз яшәүче граждан өчен – 30 мең сумнан, гаилә өчен 40 мең сумнан артмаска тиеш (индивидуаль эшмәкәрлек эшчәнлеген, үзмәшгульлекне гамәлгә ашыруда, һөнәри белем алуда һәм өстәмә һөнәри белем алуда дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә төзелә торган социаль контрактлардан тыш).

Индивидуаль эшмәкәрлек эшчәнлеген, үзмәшгульлекне гамәлгә ашыруда дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә социаль контракт төзегәндә бер тапкыр бирелә торган түләү күләме гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) социаль адаптацияләү программасы чараларын исәпкә алып билгеләнә, әмма ул 50 мең сумнан артмаска тиеш.

Һөнәри белем алганда һәм өстәмә һөнәри белем алганда дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә социаль контракт төзегәндә бер тапкыр бирелә торган түләү гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) социаль адаптацияләү программасы чараларын исәпкә алып билгеләнә, әмма ул 30 мең сумнан артмаска тиеш.»;

1.15 һәм 1.16 нчы пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.15. Дәүләт социаль ярдәме, шул исәптән социаль контракт нигезендә, түбәндәге очракларда билгеләнми:

гариза бирүче тарафыннан гаилә составы, керемнәре һәм милек хокукында үзенеке (аның гаиләсенеке) булган мөлкәт турында тулы булмаган һәм (яки) дөрес булмаган мәгълүматлар тапшырылганда;

әгәр дә гаиләнең (гражданның) мөлкәт белән тәэмин ителеше дәрәҗәсе «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына теркәлгән кушымтада билгеләнгән гаиләнең (гражданның) мөлкәт белән тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән артып китсә (18 яшькә кадәрге биш һәм аннан күбрәк баласы булган гаиләләрдән тыш);

граждан тулысынча дәүләт тәэмин ителешендә булганда;

гариза бирүче тарафыннан социаль адаптацияләү программасына һәм (яки) социаль контрактка имза куелмаганда.

Социаль хезмәтләр күрсәтүне генә күздә тота торган социаль контракт төзегән гражданнарга социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсенә бәйсез рәвештә гамәлгә ашырыла.

1.16. Дәүләт социаль ярдәме күрсәтү түбәндәге вакыйгалар барлыкка килгән айдан соң килүче айдан түбәндәге очракларда туктатыла:

граждан тарафыннан социаль адаптацияләү программасы белән күздә тотылган чаралар үтәлмәгәндә, шул исәптән:

граждан һөнәри белем алуны яки өстәмә һөнәри белем алуны вакытыннан алда туктатканда яки эш бирүчегә стажировка үтү өчен түләүне кире кайтарганда;

граждан гаебе белән хезмәт шартнамәсе өзелгәндә;

гариза бирүче тарафыннан гаилә составы, керемнәре һәм милек хокукында үзенеке (аның гаиләсенеке) булган мөлкәт турында тапшырылган мәгълүматларның дөрес булмау факты билгеләнгәндә;

социаль контракт кысаларында йөкләмәләрне үтәгәндә граждан тарафыннан акча максатчан файдаланылмаганда;

граждан социаль контракт нигезендә күрсәтелә торган дәүләт социаль ярдәменнән баш тартканда (гражданның шәхси язма гаризасы буенча);

граждан тарафыннан социаль контракт шартлары бозылганда;

гражданга иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза билгеләнгәндә;

граждан тулысынча дәүләт тәэминатында булганда;

гражданның (гаиләсенең) Татарстан Республикасыннан читтә даими яшәү урынына күченгәндә;

алучы вафат булганда.

Гариза бирүче әлеге нигезләр буенча дәүләт социаль ярдәме күрсәтүдән баш тартуга карата Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына (алга таба – Министрлык) һәм (яки) суд тәртибендә шикаять бирергә мөмкин.»;

2.1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, билгеләү өчен бу Нигезләмәнең 1.1 нче пунктында күрсәтелгән гражданнар, аларның законлы вәкилләре яки алар ышанычнамә нигезендә вәкаләт биргән затлар үзләре яшәгән яки торган урын буенча территориаль халыкны социаль яклау органына Министрлык раслаган формалар буенча гариза, шулай ук гаилә составын, керемнәрен һәм аның милек хокукында үзенеке (гаиләсенеке) булган мөлкәте турындагы мәгълүматларны күрсәтеп, гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) гаилә һәм матди-көнкүреш хәле турында анкета тапшыра.

Гариза гражданнарның дәүләт социаль ярдәме, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтүне сораган мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында кергән көндә теркәлә.

Әгәр дә почта аша яки электрон документ рәвешендә җибәрелгән гариза территориаль социаль яклау органының эш вакыты тәмамланганнан соң алынса, аларның кергән көне булып киләсе эш көне санала. Әгәр дә гариза ял яки бәйрәм көннәрендә кергән булса, аның керү көне булып аннан соң килүче эш көне санала.»;

2.2 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Гариза бирүче тапшырылган мәгълүматларның дөреслеге, алардагы документларның төп нөсхәлеге өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.»;

2.5 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5. Гариза бирүче тарафыннан тапшырылган мәгълүматлар территориаль социаль яклау органы тарафыннан үткәрелә торган өстәмә тикшерү (комиссия тикшерүе) ярдәмендә раслана.

Территориаль халыкны социаль яклау органы шулай ук граждан тарафыннан тапшырылган мәгълүматларны әлеге мәгълүматларга ия булган барлык теләсә кайсы милек рәвешләрендәге оешмаларга һәм органнарга кирәкле мәгълүматны сорап сорату җибәрү һәм алу юлы белән, шул исәптән «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә тикшерүне гамәлгә ашырырга хокуклы.

Оешмалар үзләре биргән документлардагы мәгълүматларның дөреслеге өчен законнар нигезендә җавап бирә.»;

2.7 һәм 2.8 нче пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.7. Территориаль социаль яклау органы гаризаны теркәгән көннән өч көн эчендә гариза бирүчегә аның гаиләсе яшәү шартларына комиссия тикшерүе үткәрү көне турында язмача хәбәр итә.

Гаризаны теркәгән көннән җиде көн эчендә территориаль социаль яклау органы тарафыннан гариза бирүченең яшәү шартларына матди-көнкүреш тикшерүе үткәрелә һәм социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) матди хәлен һәм торак-көнкүреш шартларын тикшерү акты төзелә.

2.8. Гаризаны карап тикшерү һәм дәүләт социаль ярдәме күрсәтүне билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул итү вакыты гаризаны теркәгән көннән 10 көн (бу пунктның өченче абзацында күрсәтелгән очрактан тыш) тәшкил итә.

Дәүләт социаль ярдәме күрсәтүне билгеләү (аны билгеләүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар хакында хәбәрнамә, баш тарту нигезләрен күрсәтеп, гариза бирүчегә, гаризаны теркәгән көннән 10 көннән дә соңга калмыйча, гаризада күрсәткән ысул белән (почта адресы буенча язма рәвештә, СМС-хәбәр итеп, электрон почта аша) җибәрелә.

Гаризаны карап тикшерү һәм социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүне билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул итү вакыты гаризаны теркәгән көннән 30 көн тәшкил итә.

Социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүне билгеләү (аны билгеләүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар хакында хәбәрнамә, баш тарту нигезләрен күрсәтеп, гариза бирүчегә, гаризаны теркәгән көннән 30 көннән дә соңга калмыйча, гаризада күрсәткән ысул белән (почта адресы буенча язма рәвештә, СМС-хәбәр итеп, электрон почта аша) җибәрелә.

Территориаль социаль яклау органы акчалата түләүләрне исәпләүләрне гамәлгә ашыру һәм «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе (алга таба – РМЯҮ) аларны алучыларга бу Нигезләмәнең 6.2 нче пункты нигезендә алга таба күчерү өчен акчалата түләүләр (айлык социаль пособие, бер тапкыр бирелә торган түләү) рәвешендә дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә билгеләү турында кабул ителгән карар хакындагы мәгълүматларны «Татарстан Республикасы халкының социаль регистры» мәгълүмат системасына кертә.»;

3.1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) социаль адаптацияләү программасын эшләү гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү үзәгенең (халыкка социаль хезмәт күрсәтү үзәге структурасындагы гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү бүлекчәсенең) (алга таба – үзәк (бүлекчә)) белгече тарафыннан гариза бирүче катнашында гариза бирүченең яшәү шартларына матди-көнкүреш тикшерүен үткәргән көннән җиде көн эчендә социаль контракт гамәлдә булу чорында гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) матди хәлен һәм торак-көнкүреш шартларын тикшерү акты һәм бу Нигезләмәгә теркәлгән 1 нче кушымтагы форма буенча төзелә торган әңгәмә кәгазе нигезендә гамәлгә ашырыла.

Гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) социаль адаптацияләү программасын эшләү түбәндәге очракларда гамәлгә ашырыла:

эш эзләүдә һәм хезмәткә сәләтле гаилә әгъзаларын эшкә урнаштыруда дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә социаль контракт төзегәндә – бу Нигезләмәгә теркәлгән 2 нче кушымтагы форма буенча;

һөнәри белем алганда һәм өстәмә һөнәри белем алганда дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә социаль контракт төзегәндә, шулай ук стажировка үткәнгәндә – бу Нигезләмәгә теркәлгән 4 нче кушымтагы форма буенча;

индивидуаль эшмәкәрлек эшчәнлеген, үзмәшгульлекне гамәлгә ашырганда дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә социаль контракт төзегәндә – бу Нигезләмәгә теркәлгән 6 нчы кушымтагы форма буенча;

гражданның авыр тормыш вакыйгаларын җиңүенә юнәлдерелгән башка чараларны гамәлгә ашыруда дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә социаль контракт төзегәндә – бу Нигезләмәгә теркәлгән 8 нче кушымтагы форма буенча.

Үзәк (бүлекчә) белгече гариза бирүчегә аның яшәү шартларын матди-көнкүреш тикшерүен үткәргән көннән өч көннән дә соңга калмыйча социаль адаптацияләү программасын эшләү көне турында хәбәр итә.»;

3.2 – 3.4 нче пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Үзәк (бүлекчә) белгече гариза бирүче белән әңгәмә үткәрү барышында әңгәмә кәгазен тутыра, гариза бирүченең сүзләреннән чыгып, аңа гаилә проблемалары, аның авыр тормыш хәленнән чыгу мөмкинлекләре турындагы мәгълүматны кертә.

3.3. Социаль адаптацияләү программасында социаль адаптацияләү буенча планлаштырыла торган чаралар, аларны үтәү вакытлары күрсәтелә, алар арасында түбәндәгеләр булырга мөмкин:

а) эш эзләү һәм эшкә сәләтле гаилә әгъзаларын эшкә урнаштыру;

б) һөнәри белем алу һәм өстәмә һөнәри белем алу, шулай ук стажировка үтү;

в) индивидуаль эшмәкәрлек эшчәнлеген, үзмәшгульлекне гамәлгә ашыру;

г) шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару;

д) балаларның мәктәпкә һәм башка белем бирү оешмаларына йөрүен тәэмин итү;

е) алкогольгә (наркотикларга) бәйлелектән ирекле рәвештә дәвалану;

ж) торак һәм хуҗалык корылмаларын ремонтлауны гамәлгә ашыру, көзгекышкы ягу чорына әзерләнү;

з) социаль адаптацияләү буенча гариза бирүченең авыр тормыш хәленнән чыгуына юнәлдерелгән башка чаралар.

Социаль адаптацияләү программасы дәүләт социаль ярдәменнән файдаланучы тарафыннан тормышка ашыру өчен мәҗбүри булган аның авыр тормыш хәленнән чыгуына юнәлдерелгән чараларны күздә тота.

Гариза бирүче социаль адаптацияләү программасын эшләү өчен хәбәр ителгән көннән җиде көн эчендә килмәгән очракта, территориаль социаль яклау органы социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүне билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итә.

3.4. Гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) социаль адаптацияләү программасы социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә бәйле булган мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия (алга таба – ведомствоара комиссия) рәисе тарафыннан карап тикшерелә һәм раслана һәм аның әгъзалары

тарафыннан социаль яклау территориаль органы тәкъдим иткән көннән җиде көннән дә соңга калмыйча имзалана.»;

4.1 һәм 4.2 нче пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Социаль контракт территориаль социаль яклау органы җитәкчесе йөзендә әлеге орган һәм гариза бирүче арасында төзелә:

эш эзләүдә һәм эшкә сәләтле гаилә әгъзаларын эшкә урнаштыруда дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә – бу Нигезләмәгә теркәлгән 3 нче кушымтадагы форма буенча;

һөнәри белем алганда һәм өстәмә һөнәри белем алганда, шулай ук стажировка үткәндә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә – бу Нигезләмәгә теркәлгән 5 нче кушымтадагы форма буенча;

индивидуаль эшмәкәрлек эшчәнлеген, үзмәшгульлекне гамәлгә ашыруда дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә – бу Нигезләмәгә теркәлгән 7 нче кушымтадагы форма буенча;

гражданның авыр тормыш хәленнән чыгуына юнәлдерелгән башка чараларны гамәлгә ашыруда дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә – бу Нигезләмәгә теркәлгән 9 нчы кушымтадагы форма буенча.

4.2. Социаль контракт төзү гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) социаль адаптацияләү программасын ведомствоара комиссия раслаган көннән җиде көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Территориаль социаль яклау органы гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) социаль адаптацияләү программасын ведомствоара комиссия раслаган көннән ике көн үткәнгә кадәр гариза бирүчене социаль контрактка имза куярга язма рәвештә чакыра.

Гариза бирүче социаль контрактка имза кую өчен чакыру кәгазе алган көннән биш көн эчендә килмәгән очракта, территориаль социаль яклау органы социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүне билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итә.»;

4.4 һәм 4.5 нче пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.4. Үзәк (бүлекчә) белгече социаль контрактны тәэмин итүне һәм гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) социаль адаптацияләү программасының социаль контракт белән билгеләнгән вакытлардагы үтәлешен аның барлык үтәлеш этапларында тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыра, аның нәтиҗәлелегенә бәя бирүне үткәрә.

4.5. Гариза бирүче белән социаль контракт территориаль социаль яклау органы тарафыннан түбәндәге очракларда вакытыннан алда өзелә:

социаль контракт буенча акчалата түләүләрне максатчан сарыф итмәгәндә (социаль адаптацияләү программасы белән күздә тотылмаган максатлар өчен сарыф иткәндә);

гариза бирүче тарафыннан социаль адаптацияләү программасы чаралары уңай сәбәпләрдән башка үтәлмәгәндә;

гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) Татарстан Республикасы территориясеннән читтә яңа яшәү урынына яки тору урынына күчүенә бәйле рәвештә;

тиешле гариза бирүгә теләк белдергән гражданның социаль контракт нигезендә күрсәтелә торган дәүләт социаль ярдәменнән ирекле рәвештә баш тартканда;

граждан тарафыннан социаль адаптацияләү программасы белән күздә тотылган чараларны үтәү барышы турында дөрес булмаган мәгълүмат (белешмәләр) тапшырылганда;

граждан (гражданның гаиләсе) бу Нигезләмә нигезендә билгеләнә торган авыр тормыш хәленнән мөстәкыйль чыккан әлеге шартлар барлыкка килгәндә.

Гаилә (ялгыз яшәүче граждан) социаль контракт төзегән территориаль социаль яклау органы үз вәкаләтләрен тормышка ашыра торган территория чикләреннән яңа яшәү урынына яки тору урынына, әмма Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә күченгән очракта, гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) яңа яшәү урыны яки тору урыны буенча территориаль социаль яклау органы социаль контрактка өстәмә килешү төзү юлы белән социаль контракт буенча хокук дәвамчысы була.

Социаль контрактка өстәмә килешү төзү өчен гражданга, яңа яшәү урынына күченгән көннән җиде көннән дә соңга калмыйча, территориаль социаль яклау органына мөрәҗәгать итәргә кирәк була.»;

6.2 нче пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.2. Акчалата түләүләр рәвешендәге (айлык социаль пособие, бер тапкыр бирелә торган түләү) дәүләт социаль ярдәме күрсәтү суммалары РМЯҮнең банкта яки башка кредит оешмасында ачылган шәхси исәпләренә күчерелә.»;

6.5 нче пунктта «Министрлыкның» сүзен «РМЯҮнең» сүзенә алыштырырга;

бу Нигезләмәгә 1 – 9 нчы кушымталар (карарга теркәләләр) өстәргә.

2. Бу карарның гамәле 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин